| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 24 февраль, 2016 ел | № 6/10 |

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен карап тикшергәч, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 28, 44 маддәләре, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 санлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 4 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 9 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 5 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11 санлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **9 маддәнең 1 өлеше 24 пунктын** яңа редакциядә бәян итәргә:

«24) каты көнкүреш калдыкларын җыю (шул исәптән аерып җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;»;

2) **28 маддәнең 2 өлеше 28 пунктында** «муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарларын» сүзләрен «муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарын» сүзләренә алыштырырга;

3) **31 маддәдә:**

- түбәндәге эчтәлектәге **7.1 өлешен өстәргә:**

«7.1. Шәһәр Советында вазифалар биләүче депутатларга Шәһәр Советы Президиумы әгъзалары, даими комиссия рәисе һәм аның урынбасары керә.»;

**- 9 өлеше 2 пунктында** «профсоюздан» сүзеннән соң «Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советыннан, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләреннән» сүзләрен өстәргә;

- **31 маддәнең 9.1 өлешен** яңа редакциядә бәян итәргә:

«9.1. Депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазифаи заты, муниципаль вазифаны биләгән башка зат 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләмәләрне, тыюларны үтәргә, вазифаларны башкарырга тиеш. Депутатның, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазифаи затының, муниципаль вазифаны биләгән башка затның вәкаләтләре, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазифаларын биләгән затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясе территориясе чикләреннән тышта урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, саф акча средстволарын һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 79-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән чикләмәләрне, тыюларны үтәмәгәндә, вазифаларны башкармаганда, вакытыннан алда туктатыла.»;

4) **34 маддәнең 2 өлеше өченче абзацында** «рәисе вәкаләтләрен» сүзләреннән соң «хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән» сүзләрен өстәргә**;**

5) **35 маддәнең 1 өлеше 4 пунктында** «муниципаль берәмлек Башлык урынбасарлары» сүзләрен «муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары» сүзләренә алыштырырга;

6) **37 маддәдә:**

- **1 өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Шәһәр Хакиме тәкъдиме белән Шәһәр Советы тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән депутатлар арасыннан Шәһәр Советы вәкаләтләре срогына үз вазифаларын даими нигездә башкаручы муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары сайлана.»;

- **3 өлештә «**муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарлары» сүзләрен «муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары» сүзләренә алыштырырга;

- **3.1 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты, Россия Федерациясе Федераль Җыены Федерация Советы әгъзасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты була алмый, башка Россия Федерациясе дәүләт вазифаларын, Татарстан Республикасы дәүләт вазифаларын, шулай ук дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын һәм муниципаль хезмәт вазифаларын били алмый; башка муниципаль

берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты яисә башка муниципаль берәмлекнең җирле үзидарәсе сайлаулы вазифаи заты вәкаләтләрен башкара алмый, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон белән билгеләнгән очраклардан тыш.»;

- **4 өлештә** «муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарларын» сүзләрен «муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарын» сүзләренә алыштырырга;

- **5 өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары шәһәр Хакиме инициативасы буенча кабул ителгән Шәһәр Советы карары буенча яисә Шәһәр Советы депутатларының билгеләнгән санынnан кимендә өчтән берен тәшкил иткән депутатлар төркеме таләбе буенча вазифадан чакыртып алынырга мөмкин. Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарын вазифадан чакыртып алу турында карар Шәһәр Советы депутатларының билгеләнгән санынnан күпчелек тавыш белән, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.»;

8) **41 маддәдә:**

- **9 өлеше 11 пунктын** яңа редакциядә бәян итәргә:

«11) каты көнкүреш калдыкларын җыю (шул исәптән аерып җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;»;

- **13 өлешкә түбәндәге эчтәлектәге 9 пунктны** өстәргә:

«9) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, шәһәр территориясендә яшәүче халыкларның телен һәм мәдәниятен үстерүгә, милли азчылыкларның хокукларын гамәлгә ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара низагларны кисәтүгә юнәлтелгән чараларны эшләү һәм тормышка ашыру;»;

9) **55 маддәнең 4 өлешендә** «муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарларын» сүзләрен «муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарын» сүзләренә алыштырырга;

10) **67 маддәнең 6 өлешендә** «шәһәр бюджетын раслау турында карар» сүзләре алдыннан «шәһәр бюджеты проекты» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Карар матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә, нигезләмәләр өчен үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевкә әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә юнәлтергә.

4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев




Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2016 елның 30 мартында теркәлгән. Дәүләти теркәү номеры № RU 163020002016001.